**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ БАКРЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАКЫРЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422384 с.Бакрчи, ул. Гагарина, 25А

422384 Бакырчы авылы, Гагарин урамы, 25А

тел. (84373) 50-2-35, факс 50-2-35, e-mail: Bakr.Tet@tatar.ru
ОГРН 1021606559512, ИНН/КПП 1638001550/163801001

**28.11.2023** **№35-1**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджеты турында ( беренче укылыш)**

1 нче маддә

1. 2024 елга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге бюджетының фаразланган гомуми керем күләме 2596,30 мең сум тәшкил итә;

2) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге бюджетының гомуми чыгымнары күләме 2596,30 мең сум;

3) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге бюджеты дефициты 0,00 мең сум.

2. 2025 елга һәм 2026 елга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) 2025 елга 2678,40 мең сум һәм 2026 елга 2764,60 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакрчы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразланган гомуми күләме;

2) 2025 елга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге бюджетының гомуми чыгымнары күләме 2678,40 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 67,00 мең сум һәм 2026 елга 2764,60 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 138,20 мең сум;

3) 2025 елга 0,00 мең сум һәм 2026 елга 0,00 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакрчы авыл җирлеге бюджеты дефициты.

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджет дефицитын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2 нче маддә

1. 2025 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының югары чиге 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының югары чиге Россия Федерациясе валютасында нульле кыйммәт белән раслансын.

2. 2026 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының югары чиге 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының югары чиге Россия Федерациясе валютасында нульле кыйммәт белән раслансын.

3. 2027 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының югары чиге 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының югары чиге Россия Федерациясе валютасында нульле кыйммәт белән раслансын.

3 нче маддә

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге бюджетында әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына фаразлана торган керем күләмен исәпкә алырга.

4 нче маддә

1.2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

2.Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджет чыгымнарын классификацияләү чыгымнары төрләренең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, төркемнәре буенча әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә бүлүне расларга.

3.2024 елга-0,00 мең сум, 2025 елга-0,00 мең сум һәм 2026 елга 0,00 мең сум күләмендә ачык норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлтелгән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакрчы авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен расларга.

5 нче маддә

Юридик затларга субсидияләр (дәүләт (муниципаль учреждениеләргә), шәхси эшмәкәрләргә һәм физик затларга товар (эшләр, хезмәтләр) җитештерүчеләргә субсидияләрдән тыш, Тәтеш муниципаль районы Бакрчы авыл җирлеге Советы карары белән билгеләнгән тәртиптә бирелә.

6 нчы маддә

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру өлешендә төзелгән килешүләргә ярашлы рәвештә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга Тәтеш муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле башка бюджетара трансфертлар күләмен расларга:

2024 елга 1,00 мең сум күләмендә;
2025 елга 1,00 мең сум күләмендә;
2026 елга 1,00 мең сум.

7 нче маддә

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге бюджетында Тәтеш муниципаль районы бюджетыннан алынганнарны исәпкә алырга

1) торак пунктларның бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр:
2024 елга-1833,10 мең сум;
2025 елга - 1902,90 мең сум;
2026 елга-1970,50 мең сум.

2) территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган җирле үзидарә органнарына беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен РФ субвенцияләре:
2024 елга - 0,00 мең сум;
2025 елга - 0,00 мең сум;
2026 елга 0,00 мең сум.

8 нче маддә

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары 2024 елда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын

арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

9 нчы маддә

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләргә ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

10 нчы маддә

Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

11 нче маддә

Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

12 нче маддә

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** **И.М.Шәмсетдинов**